**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Каракүл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25 ноябрь 2024 ел № 19

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Айбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 нче ст., Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының 23.10.2019 елның 162 номерлы "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2024 нче елның 20 нче ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Каракүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО да катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?" дигән мәсьәлә буенча беркетмә төзелде:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

"РИЗА" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 60 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 33 кеше, бу 55% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 33 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Каракүл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 нче елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлегенең Каракүл авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, МХО да катнашучылар һәм аларның

гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым акчаларын 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. 2025 елда МХО да катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (5 кеше) азат итәргә (исемлек кушымтада бирелә).

4. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р. Сафиуллин